ISSN 0136-7110

Чаян



7

САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮЛЬ * 2019 * КАЗАН

Александр ШУЛЬПИНОВ



АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Президент белән үткәрелә торган туры-дан-туры сөйләшү аңа бирелә торган сораулар үтенечләрнең елдан-ел артып баруын күрсәтә.

• Путин, Үзәк банкның Рәсәйгә кушылуы турында Нәбиуллина белән сөйләшүләр башлап җибәрде.

• Кырымны Украинага кайтаруның иң мөмкин чарасы – Украинаның үзенең Рәсәй регионы булуып китүе.

• Йортларга җылылык бирү сезоны якынлашу сәбәпле һәм коры-сары, чыбык-чабык җыюны тәртипкә салу максатында "Уполномоченный по дровам человека" вазыйфасын үтәүче булдырыла.

• Голикова Рәсәйдә ярлыларның санын киметүне үз казанышы итеп күрсәтү уңаеннан, Җәмгыять фикерен өйрәнү үзәге кискен протест белдергән.

• Эчке эшләр министрлыгы, үз хезмәткәрләренә тоткарланган кешеләрнең кесәсенә прокурор санкциясеннән башка, наркотик салуны тыйган.

• «Шырдый» агентлыгы сораштырулары күрсәтүенчә, пенсионерлар үзләренең мең тәңкәлек өстәмә бирелгән акчаларын телевизорга цифрлы приставка сатып алганнар һәм хәзер алдакчыларның ничек итеп рәхәтләнеп яшәгәннәрен карап яталар икән.

• Көнбатыш хокук саклаучылары, кара тәнле актерлар уйнамау сәбәпле, "Чернобыль" сериалын күрсәтүгә каршы чыкканнар.

• Машина йөртү таныклыгы булганнар өчен машина йөртергә өйрәтү курслары ачылган.

• Полковник Захарченко, үзендә табылган 8,5 миллиард сум акчаны ментлар ташлап киткән, дип белдергән.

• Озак тикшерүләр нәтиҗәсендә, бик зур түрәнең үзе дә оныткан йорты табылган.

• Пенсия алды пенсионерларын эш урыннары белән тәэмин итү программасы үзенең беренче нәтиҗәләрен бирде: буш шешәләр кабул итү хезмәтен кайтару тәкъдиме кузгатылды.


• Математика буенча БДИ тапшырганда мәктәп укучысы бала тапкан.

• Кроссвордлар чишү буенча дөнья чемпионатында Рәсәй охранниклары җиңү яулады.

• Йорт бөҗәкләре фәнни тикшеренү институты черкиләрнең тешләгәндә канга алкоголь сиптереп кертә торган аерым бер төрен чыгарды.

• Ялган әйберләр җитештерә торган ялган цех табылган.

Василий АЛЕКСАНДРОВ





ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел телевидениедән илдә квалификацияле эшчеләр җитмәү турында тапшыру булды. Ике зыялы белгеч уртак фикергә килде: Россиядә хатыннар аз бала табалар икән. Ә бәлки профессиональ белем алу системасын торгызып, яхшы хезмәт хакы түләп эшче профессияләренең дәрәҗәсен күтәрергә кирәктер?..

– Монда күпме тудыруның катнашы юк, әлбәттә, – диде Шомбай ага. **– Илгә эшчеләр, инженерлар, галимнәр кирәк, ә хатыннар менеджерлар, риэлторлар, экспертлар тудырып яталар...**

илдә җәй...

Эссе кояш изалыйдыр җирне –
Басуларда кибә игеннәр;
Урманнарда сайрар кошлар тынган,
Качышканнар әрлән-тиеннәр...

Кала казанында тормыш кайный:
Шәшәләргә нәрсә тутырма –
Ярсыган ат кебек эчә халык,
Потлап-потлап ашый туңдырма;
Фонтаннарда исерек десантчылар
Су коена бала-чагадай,
Карамыйча һава торышына
Эштә яна ярлы-ябагай...
Офисларда чаба кыз-егетләр,
Кайнар сәүдә бара базарда,
Нифет сатып кулга акча кергәч,
Олигарх оча Канарга...
...Коррупция белән көрәш бара,
Кабинетлар – кызган ләүкәдәй.
Ә хакимнәр аулак күләгәдә
Акча бүлә.
Илдә гади җәй.

Ринат АБЗАЛОВ

Виктор БОГОРАД



Сергей АНДРИАНОВ



Яшерен-батырын түгел: искә төшкән саен "чәй эчәргә", тамак ялгарга һәм ниһаять шәплән ашап алырга яратабыз без. Мөмкинлекләр дә моның өчен адым саен. Жаның ни тели — акчаң гына булсын. Дуслар һәм сөяркәләр белән очрашу өчен — рестораннар, эштәге тәнәфес вакытында әбәт ашарга — ашханә-кафелар, аяк өстендә тамак ялгап аласың килсә — күпсанлы ларёклар...



Авызыбызга шаурма, пәрәмәч йә кәтлит озатканда, без аның сыйфаты турында баш ватып тормыйбыз. Кызганычка каршы, бу совет ГОСТлары заманыннан сакланып калган ялгышу. Бүгенге кырыс чынбарлык башкачарак корылган — ул күпләрне төп башына утырта. Үзегез уйлап карагыз...

Грозный шәһәрендә кафеда шаурма һәм кебаб ашап утызлап кеше агуланган. Шундый ук хәл Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә дә булган. Анда урам кафесында тамак ялгаганнан соң эчәк инфекциясе белән 16 кеше хастаханәгә эләккән, аларның 3 се — балалар. Охшаш сәбәп белән Ростов өлкәсенең Новочеркасск шәһәрендә 50 кеше табибларга мөрәҗәгать иткән. Улан-Удэ каласында исә "Шудэндо" кафесында булганнан соң 113 кеше хастаханә койкасына яткан. Тик әле бу да чик түгел. Чын "рекорд"ны Тува Республикасы куйган — анда шаурма ашап 160 кеше эчәк авыруы эләктергән!

Бөтен очракларда да, рәсми документларда язылганча, "ит эшкәртүдә санитар-эпидемиологик таләпләрнең тупас бозылуы, аш әзерләү технологияләрен һәм кафе хезмәткәрләре тарафыннан шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәмәү очраклары ачыкланган" һ. б.

Бу шаукым безнең общепитны да читләтеп узмаган. Күптән түгел Түбән Камада бер гаилә әгъзаларының "Шаурма" кафесында булганнан соң күңелләре болгана башлаган. Бу ноктаны, күпсанлы кагыйдә бозулар табылу сәбәпле, тиз генә ябып куйганнар. Казанда берничә япон ашларын сөюче, эчләре авыртып, хастаханәгә кергән. Ә берничә ай элек башкаладагы бер йорт ашлары ашханәсен... тараканнар һәм күселәр өчен штрафка тартканнар. "Йорт җәнлекләре" Роспотребнадзор уздырган тикшерү вакытында табылган. Җирән тараканнар ит цехында йөгерешеп йөргәннәр, ә "койрыклы дуслар" савыт-саба юу урынында эз калдырган...

Узган елда Арча һәм Апас районнарында булган бик күп мәктәп укучыларының агулану очраклары барыбызның да исендәдер. Ул чакта ике районда барлыгы 125 бала зыян күргән иде. Бу җитди хәлдән соң барысы да аякка басты, әлбәттә. Бөтен ашханәләрне тикшереп чыктылар, җаваплылыкны көчәйттеләр, гаеплеләргә тиеш җәза биреп, отчёт ясадылар. Ләкин гомуми туклану предприятиеләрендәге сыйфат мәсьәләсе беркая да китмәде. Бизнес өчен бу уңайлы һәм табышлы өлкә, нокталар агулы гөмбә кебек үрчиләр. Аларның барысын да тикшереп торырга күпме ревизор кирәк бит... Димәк, безнең көндәлек туклануыбызны кайгыртучыларның намусына гына өметләнәсе кала.

Ә алар кулына эләккәнсез икән... Интернет бу темага рәсемнәр, видео, "Кафеда ашаганнан соң ничек исән калырга"ише киңәшләр һәм җан өшеткеч тарихлар белән тулы. Аларны карыйсың да, аппетит югала. Шуңа күрә тамагыңны өйдә туйдыруны хәерлерәк күрәсең. Һәрхәлдә, монда "кем гаепле? һәм "нәрсә эшләргә?" кебек сорауларга төгәл җавап алырга була.

Тик шулай да ресторан-кафеларның намуссыз "аш-су осталары"ның корбаны булгансың икән, нишләргә соң? Монда бары тик ике юл — башта табибка, аннан соң — судка. Статистика күрсәткәнчә, агулану буенча кузгатылган эшләрнең 80 проценты отышлы булып чыга. Әйтергә кирәк, күптән түгел суд Апас укучыларын агулаучы итеп пешекче һәм савыт-саба юучыны тапкан. Аларны 160 сәгатьлек мәҗбүри эшкә тартканнар. Ашханәгә түгелдер, дип өметләнәсе генә кала...

Равил ИСЛАМОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ





АШЫГЫЗ тәмле булсын!

• • •

– Кадерлем, нинди тәмле торт!

– «Кондитер» кибетендә алдым.

– Ә үзең шундыйны ясый аласыңмы?

– Нәрсәдән? Бездә ни натрий глутаматы, ни E517, ни E1452 юк ич...

• • •

– Официант, бу гөмбәләрне ашарга ярыймы?

– Ә сез ашап карагыз, үземә дә кызык.

• • •

Ресторанда кунак официанттан сорый:

– Сез бирә торган ашларны баш пешекчегез үзе кабып карыймы соң?

– Безнең шеф-повар ризыкны әзерли генә, аны ашап хастаханәләр буенча йөрергә тиеш түгел...

• • •

Официант өстәлгә сораган балыкны китереп куя:

– Зинһар өчен, аны тизрәк ашагыз инде!!!

– Нигә?

– Күрмисезмени, инспекция килде...

• • •

Пешекче – шәкертенә:

– Исеңдә тот, яхшы повар бернәрсәне дә ташламый. Мисал өчен, мәҗлестән соң ашалып бетмәгән кишер салаты кала икән, аңа берәр нәрсә кушып менә дигән пудинг ясарга була. Аңлашылдымы?

– Ә ашалып бетмәгән кишердән ясалган пудинг ашалып бетмичә калса?

• • •

Клиент – официантка:

– Сез бездән калган нәрсәне ашап бетерәсез, диләр, дөресме бу?

– Юк, киресенчә, сез бездән калганны ашап бетерәсез.

Илдар НӘФИЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ





Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Валерий ТАРАСЕНКО



• • •

Түрәләр белән тулган маршрут автобусында, шоферга дип җибәрелгән акча тәки барып җитмәде.

• • •

Бездә түләүсез медицина хезмәте белән бары тик сәламәтлеге нык булган эшсез кешеләр генә файдалана ала. Башкаларның моңа арлыбирле йөрерлек вакытлары да, сәламәтлекләре дә җитмәячәк.

• • •

Кызык, «Барысы да ау өчен» дигән кибетләрдә сатуда ни өчен аракы юк икән?

• • •

Өч ел тренажер залына йөрү дәверендә мин 60 мең сум ташладым.

• • •

Безнең мәче миңа тәңрегә караган кебек карый. Миннән аңа берәр нәрсә кирәк булганчы барлыгымны белергә дә теләми.

• • •

Белдерү: "Бер сәгатькә – хатын: киләм, юам, җыештырам, әзерлим, акырам-бакырам, хезмәт хакын талап алам... Кыйбат түгел!"

• • •

– Кем булып бизәнгән идең Хэллоуинга?


– Коммуналка өчен счёт булып.

– Ай-һай, куркыныч икән.

• • •

Кайбер ирләр үзләренең хатыннарын шулкадәрле нык яраталар ки, артык таушалмасыннар өчен, хәтта чит-ят хатыннарны файдаланалар.

Игорь КИЙКО



Вячеслав ШИЛОВ





СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛ

Кадерле Чаян! Гаҗәеп хәл, ләкин планетабызда кеше аяк басмаган урыннар бар икән ләбаса. Бу исә карлы поляр иркенлекләр, океан утраулары, тау биеклеге һәм Аулаш авылы зираты. Беренче санап киткәннәр табигать факторына керсә, икенчесе кешенең пошмассызлыгына керә.

20 ел элек безнең якларда тимер юл салына башлады. Зиратка керү юлын 157 нче чакрым Бегиш Никашновка ягында калдырдылар. Тимер юлны төзеп бетергәч, юлларны яптылар. Безгә исә 2 чакрым җәяү барасы яисә машинада 40 чакрым асфальт салынмаган юлдан әйләнешле. Ике юлдан да бары җәен генә үтеп була. Калган ел вакытында зиратка керә торган түгел. Әмма өченче юлы да бар: ул да булса, кыскартып – тимер юл буйлап тиз арада барып җитеп була, ләкин ул бер генә яклы булырга да мөмкин һәм соңгы тапкыр.

Аулаш авылында яшәүче халык.

Тукай районы

ЯРАМЫЙ, ДИГӘН ҖАВАП...

Хөрмәтле редакция! Әлмәт шәһәрендә дә заманага яраклаштырып, велосипед юлы төзергә булдылар. Ике тәгәрмәчне сөючеләргә бу, әлбәттә, әйбәт үзгәреш. Ләкин юлны сайлаганда халыктан бераз сораштырып сайласалар да булыр иде. Зарипов проспекты 33 нче йорт каршындагы парковканы кысрыклап, юл төзергә карештеләр. Ә бит күп катлы йорт төзегәндә машиналар куяр өчен урынны болай да бик аз калдырып биргәннәр иде. Машиналарны дыңгычлап, ике рәткә тутырасы була хәзер, ә бу исә машина хуҗалары арасында аңлашылмаучанлык кына тудырачак. Әлеге проект белән машина хуҗаларының яртысы урынсыз калачак.

Газонга якынрак юл төзүне үтенгән идек, ярамый дигән катгый җавап алдык. Янәсе, проектта каралмаган. Болай булса, безгә киләчәктә машиналарыбызны ике тәгәрмәчле лисәпидләргә генә алыштырасы кала.

В. ВӘЛИЕВ

Әлмәт

Михаил ЛАРИЧЕВ



Александр КОСМЫЛИН





Анатолий КОЛОМЕЙСКИЙ

Буй хакмәтләре

Төгәлшин фәнни казанышларга төрлечә карый иде: бер яктан, ул аларны кирәк чакта файдалана, ә икенче яктан – кискен рәвештә кире кага иде. Галимнәр кеше буеның тәүлек эчендә үзгәрүен ачыклагач, ул һәрвакыт үзе белән рулетка йөртә башлады. Алар ялгышмаган булып чыкты: Төгәлшинның метр житмеш алты сантиметрлы буе да көненә күп тапкырлар үзгәреп тора икән.

Даими үлчәнеп торулар нәтиҗәсендә менә нәрсә ачыкланды. Улы белән сөйләшкәндә аның буе ике метр тәшкил итә икән. Хатыны белән әрләшкәндә исә төрлечә: тегесе эштән соңга калып кайтса Төгәлшин ике дә егермегә кадәр үсә иде. Ә инде үзе дуслары белән гаражда тоткарланып калса – метр ярымга кала иде.

Нәчәлник кабинетында буй тагын да кискенрәк үзгәрешләргә дучар була – үлчәү өчен рулетка артык озын булып чыга, ә Төгәлшин кечкенә линейка эзләгән арада, лупа кирәк булганлыгы ачыклана иде.

Берзаман аның машинасын юл инспекторы туктатты. Тәрәзәсе аша карагач, бик гаҗәпләнде: автомобиль бара, ә эчендә беркем дә юк.

– Кара син аны – беспилотник! – дип гаҗәпләнде инспектор. – Штрафны кемгә салырга инде хәзер?

Салон идәнендәге келәм астына поскан Төгәлшин полициянең фикерләү барышына тыгылмаска булды. Инспектор машина эчен туйганчы телефонына төшереп, китеп барды. Төгәлшин шунда ук өенә шалтыратты:

– Теге хөрәсән үзенең «икеле»ләре белән хәзер үк минем янда булсын!

– Ә улыбыз бүген «өчле» алган! – дип мактанды хатыны.

– Шул гына житмәгән иде! – дип сүгенеп куйды Төгәлшин, умырткасын турайтып. – Алайса кием-салым кибетендә үзең акча туздырып кайт инде, ичмасам!

– Ә мин нәкъ шуннан кайтып киләм дә инде! – диде гаепле тавыш белән хатыны.

Хәләленә туйганчы акырганнан соң, Төгәлшин үзенең гадәттәге метр житмеш алтылы хәленә кайтты һәм рульгә утырып, кузгалып китте.

Абау!

РИЗЫК ӨЧЕН ЯРДӘМ

Чаллыда Татарстанның дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәре үзенең хезмәт мөмкинлекләреннән файдаланырга булган. Ике эшмәкәргә ул 5 мең сумга алкоголь сатуга лицензия вәгъдә иткән, ә тагын бер бизнесменнан сыра белән сәүдә итүдә ярдәм өчен 6 мең алган, ә бер кафены гомумән үз "канаты" астына алган. Хуҗаны законсыз сәүдә өчен җәзадан саклап, ханым аның өчен... түләүсез азык-төлек алган. Кылган гамәлләре өчен чиновник хатын дүрт статьяга эләгүгә карамастан, аңа бары тик шартлы срок биргәннәр. Суд моны инспекция хезмәткәренең өч баласы булуны истә тотып эшләгән.

МАТУРЛЫК ПРЕМИЯ СОРЫЙ

Чаллыдагы алюминий профильләр житештерү белән шөгыльләнүче "Татпроф" компаниясе гадәти булмаган премияләр керткән. Барлык хатын-кыз хезмәткәрләргә эш урынында үтәлгән дресс-код (тиешле кыяфәттә йөрү) өчен көненә 100 сум түләнә. Компания житәкчелеге фикеренчә, һәр хатын-кыз күлмәк йә юбка кигән булырга, чәчләре җыелган, жиңелчә макияж булырга тиеш. Бу чараның максаты – хезмәткәрләрнең 70 процентын ирләр тәшкил иткән коллективта эш барышын матурлау һәм жиңеләйтү икән.

ҮЛЕМНӘН КОТЫЛУ ЮЛЫ

Лениногорск пекарнясының яшь сатучысы белән таныш булмаган хатын сөйләшеп киткән. Ул 26 яшьлек кызны тормышының бик начар юнәлештә баруына ышандырган. Үлемнән бердәнбер котылу юлы – акча бирү, имеш. Куркынган туташ шунда ук алтын алкаларын, үзе белән булган 3 мең сумын һәм әле тагын кассадан 20 мең алып биргән. Өч көн узгач, алданганын аңлап алган һәм полициягә мөрәҗәгать иткән. Хәзер үткен хатынны эзлиләр.

ЯКТЫ КИЛӘЧӘК ӨЧЕН

23 яшьлек Казан егете кайчандыр үзе эшләгән автомойканы баскан. Ул аннан 126 сумлык автомобиль юу һәм чистарту кирәк-яраклары алып киткән. Моны үзенең киләчәге хакына эшләгәнен әйткән. Киләчәктә үзе автомойка ачып, урланган әйберләрне шунда файдаланырга җыенган икән.

























Алексей МАМАЕВ

Валентин ДРУЖИНИН



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Игорь КИЙКО





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Сезнең алгебрагыз нигә кирәк ул миңа? Аның беркайчан кирәге булмаячак ич!

– Бер егерме-утыз елдан улың белән дәрес әзерләгәндә белерсең әле аның нигә кирәк булганын!

• • •

Мединститутны тәмамлаган яшь табиб район хастаханәсенә килә.

– Авыру тарихында кыскартып язылган авыру исемнәре нәрсәне аңлата? – дип сорый ул.

– Авыруларның психикасын җәрәхәтләмәс өчен эшләдек аны: ИМ – инфаркт миокарда, АЯШ – ашказанында шеш...

– Ә нәрсә ул КБА?

– Кем белгән аны...

• • •

Хоттабыч картның яшь хатын алып бер ай үтүгә, сакалы коелып бетә.

• • •

– Әлү! Бу шөгыльлек үзәгеме?

– Әйе.

– Сездән бурычка алып тору белән шөгыльләнергә буламы?

• • •

Криминаль яңалыклардан:

"Ике ярым кеше зоопаркта крокодилны урларга маташканнар".

• • •

– Без аерылырга тиеш. Тик эш синдә түгел, ә миндә.

– Ә сиңа нәрсә булды соң?

– Минем синнән күңелем болгана.

• • •

"Без яхшырак яши башладык!" – диде хөкүмәт.

"Без сезнең өчен шатбыз!" – дип уйлады халык.

• • •

85 яшьтән узган һәр ир кешегә җиде хатын-кыз туры килә. Ләкин соң шул... Бик соң.



Дамир МОРТАЗИН

БИЛ АВЫРТУ ГАЛӘМӘТЕ

Тиктомалдан бил авырта башлады бит әле. Әллә җил бәрде микән? Иртән торсам ни бөгелеп, ни сыгылып булмый. Эшкә дә, таяк сыман, туп-туры басып бардым.

Вахтадагы Илшат, минем аңа сәлам дә бирмичә, хәтта елмаймыйча-нитмичә үтеп керүемне күргәч, ачулы күзләрен шарландырып калды: караны, эштән биш минутка алдан чыгып китәсең бар, янәмәсе...

Коридорда бухгалтер Роза очрады. Мин аңа да сәлам бирә алмадым, ул да йөзендә канәгатьсезлек билгесе чыгарды:

– Ай-яй, әллә кем булган, югарырак урындагы кәнәфигә утыргач!

Офистагы хезмәткәрләр, компьютерларыннан арынып, миңа шелтәле караш ташладылар. Ничек шулай булмасын! Мин бит аларга баш иеп тормыйча, тыныч кына барып, өстәлем артына елыштым. Ничек итеп аңлатыйм соң, билем бөгелмәгәнен?

Төш вакытында гомуми эшләр буенча урынбасар Гани Ганиевич белән чут бәрелешми калдык. Ул читләп үтмәкче иде, ләкин минем аңа, гадәттәгечә, баш имичә үтеп баруымны күргәч туктады һәм теш аша ыслап:

– Ну яшьләр китте хәзер, өлкәннәргә бөтенләй хөрмәт юк! Менә безнең вакытта... – дип үзенең авылда үскән чорындагы хатирәләренә чумды. Билнең авыртуына түзеп, мин эш бүлмәсенә ашыктым. Карыйм, каршыма фирмабызның генераль директоры Вәли Вәлиевич килә. Кыяфәтемә һәм рәвешемә карап туктады да, күрсәтмә бирә башлады:

– Хәбиров! Артык һавалылык – безнең фирма хезмәткәре өчен бик үк килешеп бетми торган сыйфат, бигрәк тә һәр ел саен була торган аттестация алдыннан. Колагыгызга элегез бу турыда һәм үзегезгә нәтиҗә ясагыз!

Кичен хатын минем сызлаган билемә кайнар кирпеч төреп куйды – бу бит инде халык тарафыннан сыналган иң яхшы чара.

– Борчылма! Иртәгә чиреңнең эзе дә калмас! – диде ул...

ТҮЗЕГЕЗ!


Дмитрий Медведев тарафыннан әйтелгән байтак сәер фикерләренең берсе:
"Акча юк, ләкин сез түзегез!"

Яратабыз Синең йөрешеңне,
Алпан-тилпән атлап килешеңне...
Син түгелме идең – Шәп Президент!
Шәп Премьер – мәңгелек Претендент!..

Син бирәсең безгә яшәү рухы,
Авыр чакта төпле киңәшеңне.
Әле күптән түгел Рәсәй халкы,
Аңлап авыр эштә эшләвеңне:
"Акча юк, ләкин сез түзегез!" – дип
Хәлгә кереп, әйткән сүзләреңне.

Әллә булышыйммы? Оялма Син,
Сора: "Чирен яшергән бит – үлгән..."
Акчаң булмаса тәүбә: димәк ки,
Без инде... түзгән-түзгән дә, түнгән...

Алмаз ХӘМЗИН



Александр СЕРГЕЕВ

Антон МАКУНИ

ШУЛАЙ ЯШИБЕЗ

Сихерчеләр, күз буучылар, экстрасенслар, күрәзәчеләр...

Минә безнең подъезддагы соңгы катта яшәүче хатын бөтен нәрсәне алдан белеп, күреп торучы! Хәтта стена аркылы да күрә. Алай гынамы соң, түшәм аркылы! Йортыбызга илле еллап ремонт ясалмаганга, түшәме тоташ тишекле...

Ә минем эшемдәге җитәкчем – Гали Мәхмүтович – күрәзәче! Андый тылсымчыны бүтән җирдән эзләп тә табалмыйсың! Ул ике кеше булып әверелә ала. Пространствода һәм вакытта. Хатын аның эшенә шалтырата, ә аңа болай дип әйтәләр: "Ул объектта". Нинди объект? Ул икеләнергә өлгергән! Гали – объектта, ә Мәхмүтович – сәяркәсе белән ресторанда...

Ә иң өстә? Менә кайда алар гипнотизерлар һәм копперфильдлар! Күрәзәче өстендә күрәзәче, тылсымлашып беткәннәр! Бәяләр күтәрелә, ләкин доллар төшә. Нефть очсызлана бара, ә бензин кыйбатлана. Ил байый, ә күттә ыштан тормый... Рейтинглар үсә, әмма бөтенесе дә бәхетле! Менә сиңа гипноз! Менә сиңа багу!

Кая ул башкалар турында әйтеп тору? Мин үзем дә рухлар арасында арадашчыга әйләнәм. Бакырны бушлыкта бутыйм! Башка металларны да. Күптән түгел генә бер җиз һәйкәлне күчердем, хәтта берәү дә сизми калды. Бер генә адәм заты да... Анда аларның якын да килгәне юк, чөнки һәйкәл зиратта тора иде, ә бу эш төнлә эшләнде...

Ә сез, сихерчеләр, күз буучылар, экстрасенслар, күрәзәчеләр, дисез... Әгәр дә ныграк уйлап карасаң безнең һәрберебез нинди дә булса сихерче, нәрсәдә булса да күрәзәче рухлар белән эш итүче экстрасенс. Әлбәттә, акыл һәм сәләтеңне җигеп эшләсәң. Шуңа бактык, багабыз һәм дә багачакбыз!





УРТАЧА ЛИМИТ

Хисап палатасы пенсионерларның ничек яшәгәннәрен тикшергән. Ил буенча уртача пенсия 14 мең сум, шуннан коммуналь түләүләрне түләгәч, кирәкле даруларны һәм шәхси гигиена кирәк-яракларын сатып алгач, пенсионер үзенә көненә 200 сум акча тота ала. Идарә уйлавынча, мондый кызык сумма булуында демография гаепле – эшләүче халык елдан-ел кими. Күптән түгел күтәрелгән пенсия яше җиңелчә генә бу мәсьәләне бераз җиңеләйткән, тик тулысынча аны чишә алмаган.

АРТЫК ӨЛГЕРЕШ

Төмәннең Дәүләт аграр университетының студентлары яхшы укыганнары өчен зыян күргәннәр. Яхшы уңышлары өчен аларга стипендияләрен киметкәннәр. Гади стипендияне 3,8 мең сумнан 2,7 гә кадәр киметкәннәр, ә яхшы укучылар яртысын югалтканнар – аларга хәзер 10 мең урынына 5 мең сум түлиләр. Моны университетта уңышлы сессия бирүчеләр санының өч тапкыр артуы, ә стипендия фондының шул килеш калуы белән аңлатканнар.

НӘСЕЛ-НӘСӘПСЕЗ

Уфадагы пенсионер хатын коммуналь түләүләр буенча җыелган 300 мең бурычыннан котылу өчен үз исем-фамилиясеннән баш тарткан. Людмила Киселева үзенең барлык документларын юкка чыгарган һәм миграцион хезмәткә аны бөтен базалардан алып ташлауларын сорап мөрәҗәгать иткән. Хәзер ул үзен һәм бурычлы Людмила Киселеваның бер үк кеше булуын танырга теләми. Пенсионер үзен «тере Людмила» дип атый, ә фатирына «табигый туу хокукы» буенча хуҗа.

АҢСЫЗ НИКАХ

Кузбассның Таштагол ЗАГСы мөдиренә танышы сырхауханә койкасында аңсыз яткан ир белән никах теркәүне сорап мөрәҗәгать иткән. Өйләнешү булган, тик кияүнең ризалыгын берәү дә сорап тормаган. Бер көннән соң «яшь кияү» үлеп киткән, ә өлгер хатынга аның бөтен мал-мөлкәте калган. Ә мөдирне үз хокукларын арттыруда гаеплиләр.



Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 11, 2002



Илдар ӘХМӘДИЕВ, «Чаян» № 7, 1999



Вячеслав БИБИШЕВ, «Чаян» № 18, 2007

ИШТИРӘК ШАГЫЙРЕ ГАБДЕЛХӘЙ МЕТШИН

Кызганыч...

Табигать биргән сәләтләр шул килеш калды.

Жәл.

Бик жәл.

Нишләп шулай булды?

Артык тыйнак идеме?

Шул комачау иттеме?

Габделхәй Метшинның сабакташы, якын дусты, халык шагыйре Зиннур Мансуровның бу турыда үз фикере бар:

– Габделхәй артык гадел иде. Артык ихлас иде. Аннан зур татар шагыйре чыгарга тиеш иде. Шигърият юлыннан китмичә, фән юлыннан китсә дә, аннан татарның зур галиме чыгарга тиеш иде. Тагын бер шәп сыйфаты бар иде Габделхәйнең – коеп куйган рәссам иде бит ул. Бу юлдан да китәргә мөмкинчелеге юк түгел иде – тулай торак буйлап кулдан-кулга без укыганда күпме рәсемнәре йөрде бит аның. Ул бит беренче курсларда укыганда ук университетны тәмамлаган кешеләргә диплом эшләре язып бирә иде!

Шулай. Бөтенесе дә бар. Артык талантлылыгы да бар. Артык тыйнаклылыгы да бар. Артык гаделлеге дә бар. Артык ихласлылыгы да бар. Артык нечкә күңеллелеге дә бар. Бөтенесен плюс, бер генә минус та юк.

Ләкин шунда...

Их, бераз гына...

Миллиграмм гына...

Үҗәтлеге булса иде аның!

Габделхәй Метшин әдәбиятка бик югары таләпләр куя иде.

Сеңлесе Мәдинәгә, еллар үткәч, аның ни өчен әдәбиятны, язуны ташлавының сәбәбен сорагач, ул болай ди:

– Тукай чаклы яза алмасаң, язып торасы да юк!

Әле дә хәтерлим, 1965 елда, мин үзем язган беренче шигырьләрне күрсәтергә Габделхәй Метшинга төштем. Әнисе Нурия апа – бик йомшак күңелле, ифрат кунакчыл кеше иде – мине зурлап, өстәл янына утыртып, чәй эчертте. Габделхәй абый миңа шигырьдәге ритм, рифма турында сөйләде.

Кыскасы, мин бишенче, алтынчы, хәтта җиденче классларда чиле-пешле шигырьләрне блокнот-блокнот яздым. Аның заманы шундый иде – хәзерге сыман телефон юк, компьютер юк, телевизор юк... Язганнарны ул вакытта инде шигырьләре район газетасында, республика матбугатында еш кына күренеп-күренеп киткән Габделхәй Метшинга күрсәтеп барам. Бервакытны бер җәйге кичне клуб артындагы озын баскыч төбендә басып торабыз, мин аңа шигырьләрне бирдем, ул укый. Почерк – тараканны карага манып җибәргән кебек.

– Көнчыгыштан чыга алмый кояш... Чыга алмый кояш... Аңлашылмый бит әле бу, Рафис...

– Алмый түгел бит ул...

Мин блокнотны үз кулыма алып, "шедеврны" тулысынча укып күрсәтәм:

Көнчыгыштан чыга алтын кояш,
Керәч Тауга төшә нурлары.
Томан күтәрелә дулкын-дулкын,
Ямьләнә Иштирәк буйлары.

Рафис СӘЛИМҖАНОВ

ХУҖА

Виктор ВЕСЕЛОВ

Экспедитор Мәмиев рубероид рулоннары төялгән өченче фураны бушатып бетерде дә, эскәмиягә барып утырды. Ләкин бер минут та үтмәде, каяндыр өстән склад мөдире Ташбаеваның усал тавышы күкрәде:

– Нәрсә эшең беттеме әллә?

– Менә мин… – дип башлады сүзен экспедитор.

– Әле генә бушатып бетердем…

– Кулыңа себерке ал да складны чистартып чык!

– Мин җыештыручы түгел, ә экспедитор! – дип кычкырды Мәмиев эченнән генә һәм себерке алырга китте. Эшен бетереп, тагын эскәмиягә барып утырды. Һәм шунда ук Ташбаеваның тавышы ишетелде:

– Шөгыль табалмыйча утырасыңмы? Табармын мин сиңа эш!

– Утырдым гына… – дип башлады Мәмиев.

– Әле генә радиаторлар белән машина килде. Сораулар бармы?

– Бар! – дип акырды ул эчтән бар көченә. – Мин кем — экспедитормы, әллә йөкчеме? Бар да үзең бушат…

Парын чыгарып, Мәмиев машинага таба юнәлде.

Соңгы радиаторны ул инде көч-хәл белән, этеп алып барды. Аны урынына куйгач, бер минут буе үзе себергән идәнгә җәелеп ял итте.

– Кара син аны? – дип дулады Ташбаева. – Сузылып яткан! Ә койманы кем буярга тиеш?!

– Мин экспедитор, буяучы түгел, – дип пышылдады кипшенгән иреннәре белән Мәмиев, һәм тавышын көчәйтеп сорап куйды:

– Пумала бирәсезме, әллә өйдән алып килимме?

– Бирәм инде, ялкау, бирәм, – диде склад мөдире. – Синнән йөз сум!

Авыр сулап, экспедитор аңа хатыны әбәткә дип биргән йөзлекне сулды.

Эштән кайту белән Мәмиев өендә тәртип урнаштырырга тотынды. Беренче итеп эш ишек янында яткан этне һәм аягына сырпаланып торган мәчене тибеп очырды. Аннан соң саңгырау кайнанасына җикеренде. Мәмиевнең тәрбиясеннән соң карчык ишетә башлады, һәм кулына чүп чиләген элэктереп, ишегалдына чыгып чапты.

Залга кергәч, йорт хуҗасы коточкыч манзарага тап булды. Бөтен гаилә өстәл янында утыра, хатыны китап укый, ә балалар, авызларын ачып, аны тыңлап утыра.

– Эшлексезләр! – дип кычкырды Мәмиев. – Нәрсә, эшегез беттеме әллә?! Мин сезгә эш табармын! Торыгыз да, кулыгызга чиләк белән чүпрәк алыгыз! Өй ялт итсен!

Игорь КИЙКО



Иван АНЧУКОВ



БЕР ТЕМАГА – ИКЕ ШИГЫРЬ

ӘГӘР ТУКАЙ ТЕРЕЛЕП КАЙТСА


Ел да шулай...
Яз җитәрәк,
Башлана ыгы-зыгы.
Керсезе дә, әрсезе дә
Тукай бүләге даулагач,
Бетеп бара кызыгы.
Арада кемнәр генә юк:
Рәссамнар, төзүчеләр.
Иҗаттан җәяүләп качкан,
Нәфесле көнлекчеләр.
Әгәр Тукай терелеп кайтса,
Ни әйтер бу хәлләргә?
Тукай бүләгенә түгел,
Бары "күкәй" бүләгенә
Лаеклы адәмнәргә!

Камил СӘГАДӘТ

Без – кемнәр соң?..
Әйтә алмыйм...
Кешеме, хайваннармы?..
Бүләк бирәбез, дисәләр,
Онытабыз кешелекне,
Әдәпле кануннарны.
Онытабыз Алла барын,
Югалтабыз намусны.
Иман, әхлак диган мәгънә
Кача бездән, ахрысы.
Атаң биргән исемеңне,
Акла гына югыйсә!..
Йөрмә Тукай бүләгеннән
Абруй ясап, борын чөеп,
Акча өчен бер кесә!..

Алмаз ХӘМЗИН

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Рашат НИЗАМИ

КИСЛОРОД

Тын алыйм дисәң, кайчакны
Һава җитми кешегә.
Туры килер микәнни соң
Кислород бүлешергә?..

ТАШ

Матур сүзләр сөйләмичә генә
Мин бит сине ихлас яраттым.
Алсу алма түгел, бер сүз белән,
Ә син йөрәгемә таш аттың...

ТАБЫШМАК

Дөньялыкны танып-белер өчен
Сикереп төштек кабык арбадан...
Ә дөньямы? Әле булса үзе
Аера алмый акны карадан,
Нишләргә соң инде, фаразан?

КУРЧАК

Депутатлар – курчак кына бездә,
Ни кушсалар, шуны үтиләр.
Азатлыкны дәгъва итеп, әнә,
Митингка чыга түтәйләр.

Александр АЛЁШИН



Нияз БИШБАЛТА

ТАБИБЛАР НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?..

Күпләребез табиблардан ярдәм көтә. Узган атнада башым бик авырткач, сырхауханәгә барган идем. Яшь табибә кыз кабул итте. Башым авырта дип әйтеп торам, ә ул арт ягыма укол кадады.

Эчем авыртып табибка кердем, авызыңны ачып, телеңне күрсәт, диде.

Терапевт – табиб түгел, түрәләре әйткәнне генә үтәүче.

Хирург – сапер кебек, бер генә ялгыша.

Психиатр Җир шарындагы барлык кешеләрне үзенең пациентлары итеп карый.

Дерматолог – кирәкле табиб. Сезгә унитазда яки башка аулаграк урында нәрсәләр яшерелгәнен белү кызыкмы? Ә ул аларны күреп таный.

Уролог – бик тар карашлы белгеч, сексопатолог булмаса да, һаман ыштан тирәсендә маташа...

Травматологлар спортны ярата. Бизнес...

Ревматологка ышаныч юк, гадәттә, аның янына килүчеләрне дәваларга соң...

Патологоанатомнар – югары профессиональ табиблар. Ул һәрвакыт кешенең кай җире авыртканын, ни сәбәп белән аяк сузганын ялганламыйча төгәл әйтеп һәм язып бирә ала.

Табиблар менә шундый булырга тиеш.



Кәшфи ШӘРИПОВ

ИРЛӘР СПОРТЫ

– Хәзер, спортка иң югары дәрәҗәдә игътибар артканда, үзеңә берәр төрлесен сайлап алу вакыты, – дип уйлады да Галиев, диваныннан торды. – Теннис, дзю-до, хоккей… Җаның кайсын тели!

– Иң әйбәте футбол, ләкин анда гел кемне булса да сату һәм алу бара, бу өлкәдә финанс мәсьәләләрен яхшы белү таләп ителә, ягъни үзеңне арзанга сатып җибәрмәсеннәр өчен…

Бокс, әлбәттә, чын ир-атлар спорты, бигрәк тә үзең бәргәләгәндә, ә менә үзеңне тукмый башласалар – бу инде хулиганлыкка әйләнә…

Трамплиннан сикерү ничек? Безнең өйдән чыккач, кая сикерергә белмисең, кая барып төшәсеңне абайламыйсың, инде трамплиннан сикерү турында уйларга да кирәк түгел. Гомумән, кышкы спорт төрләре белән маташырга теләсәң, тән мыҗырдап куя…

Көрәш, менә әйбәт спорт, ичмасам, ләкин келәмдә көндәшең – бер белмәгән мужик белән кочаклашырга туры киләчәген уйлыйсың да, әллә ничек булып китә…

Җиңел атлетика – үзеңнең чыгыш ясау чыратың җиткәнче бөтен теләгең бетә дә куя, ярышасы да килми.

Ядрә яки тәлинкә ыргыту һәм йөгерү нигәдер күңелгә ятып бетми, монда әле көне буе анда-монда чабып йөреп тә хәл бетә…

Сәпидтә ярышу – анысы да әллә нинди спорт, көн саен эштән өйгә кайтып китеп йөрү дә ардырта, туйдыра, шунысы да бик җиткән.

Спортта кайнашу ул бит әле бик чыгымлы нәрсә, кызыктырган саен, күбрәк акча кирәк. Юк, бераз тамак чылатып алмыйча юньле фикергә килеп булмас, мөгаен!

Галиев үзенең дусты Вәлиевкә шалтыратты да, икесе дә бер уйда: ике чәкүшкә алдылар һәм телевизордан футбол карап утырырга кирәк булыр дигән фикергә килделәр. Менә, ичмасам, монысы чын ирләр спорты!







...Житәкчеләргә, оештыручыларга, җаваплыларга дип әйтүем. Сабан туе турында сүзем. Туганнан бирле беләм инде мин аны: шулай дип әйтеп башласам һич артык булмас. Көрәшкән дә булды, атта да чабыштык, йөгерүдә дә катнаштык, чүлмәк тә ватыштык, катыкка да чумдык, баганага да мендек, капчык белән дә сугыштык, гомумән, ни генә кыланмадык, ә менә шул мавыгулардан үзебезгә тапкырлык та, хәйләкәрлек тә, көч-егәр җыйганны, намус-вөҗдан да тәрбияләнгәнлеген сизми калганбыз. Болары без – егетләр өчен булган, ә менә кызларга ни хикмәт сеңгән бу бәйрәмебездән? Күз алдына китерегез – су ташу ярышы: чигү чиккән кебек, җитез адымнар белән иңнәренә көянтә-чиләк асып кызлар атлый. Нәрсәгә тиңлим икән?.. Аккошларга?.. Юкюк, алар тиңдәшсез!.. Татар кызлары! Чиләкләреннән ник бер тамчы су түгелсен, ник бер тамчы!.. Егетләрнең күзләрендә чамасыз соклану чаткылары. Менә кайда икән бит аларга тиң ярлар – булачак киленнәр! Хезмәттә – уңганлыкта, булганлыкта сынатмас тормыш юлдашлары!

Мәйдан уртасында егетләр бил алыша. Батырга бүләк – чиккән сөлге, килен булып төшкән яки төшәсе чибәркәйдән! Үзе, үз куллары белән чиккән бит ул аны. Моннан да зур бүләкнең булуы мөмкин түгел! Ә сөлгеләр байтак – барысының да очларында бизәк, чук – уңганнардан. Әйе, әйе Сабантуйда кул эшләре дә ярыша – хезмәт бәяләнергә тиеш!..

Мәйдан гөрли, мәйдан шаулый! Атлар килә, атлар! Тузанлы юлның тузанын кубарып, томырылып атлар чаба. Һәркем үз авылының җайдагына көч биреп, җан ата: "Җәүдәт, Җәүдәт! Рәшит, Рәшит! Миңнулла, Миңнулла! Әйдә, малкай, әйдә, әйдә!"

Мин шуларны күз алдына китереп, хатирәләргә чумып утырам. Их, бар иде бит шундый Сабантуйлар! Бар иде бит! Кайда алар хәзер?!.

Ишеткәлим, быел фәлән авылда Сабан туе булмаган. Кайбер җирләрдә район үзәгендә генә үткәрәләр икән дә, вәссәлам: Казанда да, элегрәк, район саен узгаралар иде, хәзер анысы да юк. Кызганыч, сугыш еллары булуга карамастан, бу бәйрәмнән мәхрүм итмәгәннәр. Ә менә Америкага барып үткәрәләр, Австралияне дә калдырмыйлар, әле менә хәзер Парижның Эйфель башнясы төбенә барып Сабантуй оештыру да гадәткә кереп бара. Шәп бит, диярсез! Булдырабыз, диярсез! Әле үзебезнең Сахалинны да калдырмыйбыз, Владивостокны да. Житешәбез, күкрәк кагып горурланабыз, вәт, без татарлар, ичмасам, әйеме?! Акчабыз күп, Җир шары әйләнәсе буйлап чәчеп йөрибез. Ә үзебезнең мондагы Сабан туе үткәрерлек мөшкел хәлебезгә – кесәбез тишек. Барып кайтучылар: «Йөз кеше бардык, ун кеше карады. Концерт куеп кайттык», – диләр. Ярый, мәйтәм, үзегез дөнья күреп кайткансыз бит, дим. Ел саен шулай йөриләр икән. Вәт, малай, рәхәт кайда ул!

Уйландыра. Ул хәтле, милләт, дигән булып, кандәшләребез дип җан атып йөрмик әле. Алар, алай ук беткән кешеләр түгел, Сабантуйлык мохтаҗлык та кичермиләрдер. Андыйларны чит илгә акча эшләргә, баерга киткән кешеләр дип беләм мин. Елга бер кайтып, Сабан туе карап китәрлек, чын бәйрәм күреп, дусларын, туганнарын кочып, туган ягын, авылын, шәһәрен айкап йөрерлек хәлләре дә, мөмкинчелекләре дә безнекеләргә караганда күбрәктер дип беләм. Ә менә безнең әби-бабайларыбыз Казан Кремлен күрергә килгән 90 ышар яшьлек немесләрне карарга да хәлләре юк. Тегеләр рәхәтлек кичереп, илләр гизәләр. Без монда якындагы бер Сабан туебызга чыгып керергә – заринтизар. Нужәли тора-бара Германиягә барып карарга туры киләчәк?!

Төгәлрәк шуны әйтәсем килә: Сабан туебыз – тиңдәшсез зур бәйрәм. Милли байлыгыбыз, хәзинәбез. Аны, Сабантуй, дигән булып чит илгә чыгарып йөрергә түгел. Ул анда чын милли йөзен күрсәтә алмый, шуңа күрә беркайчан да танылa алмаячак. Булган финанс мөмкинчелегебезне, бу өлкәдәге белдеклегебезне җыйнап, үз илебездә бу бәйрәмнән бренд ясарга кирәк. Менә дигән итеп, шаккаттарлык, сокланырлык, горурланырлык итеп. Моны татарлар гына булдыра ала, дисеннәр. Кайтсыннар татарлар чит илләрдән, менә дигән Сабан туе карасыннар, безнекеләр булдыра, дисеннәр! Акчалары илгә кайтыр, ватаныбыз куәтенә. Үзебезнең кадерне белеп яшик әле, җәмәгать!

Алмаз ХӘМЗИН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 7 (1885) июль 2019

Баш редактор
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
А. АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН, Л. ӘХМӘТОВА, Г. СӨНГАТУЛЛИНА,
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 05.07.2019 ел.
Тираж –1130 Заказ О-1691

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

ДЕЛЕГАТ

ЖЫРЧЫ ИСКӘНДӘР

. . .

ТАҢНАРЫ"

ХАЛЫК ЖЫРЫ

11

"КОШ БАЛАСЫ КАНАТ БЕЛӘН . . ."

ГЫЙБӘДӘТ

2

ЖУРНАЛИСТ

ӘМИНОВ

ЧӘЧӘК

8

"ЖИЛФЕР-ЖИЛФЕР ДИМ-ДИМ . . . ЧУКЛАР ДИМ-ДИМ"

МӘЙДАН БИРӘМЛЕГЕ

17

5

12

"КЫЗ" СЫЕР

БЕР . . . ИПИ

ТӨССЕЗ БУЯУ

"ИТИЛ СУЫ . . . ТОРУР"

"КЫЙГАК-КЫЙГАК, ИЛЕМ . . ."

ТЕЛӘК(-1)

" . . . КАТЫ АГА"

16

«БАЛА» ИСКЕЧӘ

ШАХМАТ ФИГУРАСЫ

"ИР-ЕГЕТЛӘР КИТТЕ . . . КЫРЫНА"

"ӘРӘМӘДӘ . . ."

РӘССАМ НИКОЛАЙ . . .

ИШАРӘ

7

10

14

3

13

" . . . ПАРОХОД"

РОССИЯДӘГЕ ЯРЫМУТРАУ

4

" . . . КАНАТЫ"

АШ САВЫТЫ

НОТА

"БАЛА КҮНЕЛЕ . . . ДА"

АТТАН ДА . . . ТУА, КОЛА ДА ТУА

НОТА

АВИАКОНСТРУКТОР

АЕРЫЛГАННЫ АЮ . . .

ЖЫРЧЫ . . . ВӘЛИЕВ

. . . ЧӘЧ

" . . . ТӘРӘЗӘӘҢ, КҮТӘР ПӘРДӘҢ"

1

"ШҮРӘЛЕ, ЖЕН . . . ҺӘМ . . ."

6

19

БИРГӘН — БИКӘ КИЛЕН"

УҢАЙ ЭЛЕКТРОД

" . . . АККОШ"

ЙӨЗҮ ЖАЙЛАНМАСЫ

" . . . КИРӘК"

ЖЫРЧЫ ЗӨФӘР . . .

9

"БИК САГЫНДЫМ . . . БУЙЛАРЫН"

ТАРТТЫРГАН ЯРМА

18

15

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Куркынычсыз җенси мөнәсәбәт нәрсә ул?

2. Эт сөйләшә башласа, нәрсә була?

3. Ни өчен сырны чит илдән кертүне тыйдылар?

4. Хатыныңның хыянәт итүен ничек белергә?

5. Намуслы да, бай да булып буламы?

6. Туйны хәтердә калдыруның иң яхшы ысулы?

7. Дәвалап булмый торган сәламәт кеше.

ҖАВАПЛАР

1. Хатының бу турыда беркайчан да белмәгәндә. 2. Кеше соңгы дустын югалтачак. 3. Пальма мае кушып ясалган сырны башка нәрсәләр белән чагыштырырлык булмасын өчен. 4. Аңа бүтән кеше аркылы чәчәк бәйләме җибәрегез, әгәр дә ул өегезгә чәчәксез кайтса – димәк, хыянәт итә дигән сүз. 5. Әйе, ләкин башта бай булырга тиеш ул. 6. Аны үткәрү өчен кредит алырга кирәк. 7. Симулянт.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе — **«ТУЛА МИКӘН ЧИЛӘГЕ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

З. БАТЫРОВ (Ульяновск),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Д. НУРУЛЛИН (Казан),
З. МӨХТӘРОВ (Тәтеш р-ны, Кече Тархан ав.),
Ә. ХӘСӘНОВА (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Кече Тарханнан

Зөфәр МӨХТӘРОВ!



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Гәрәй РӘХИМ

САБАН ТУЕ

Уйна, гармун, җырла, курай,
Әйттер шуны, әнә шулай –
Сынатма!..
Сынатма!..

һоп!.. һоп-па!..
Сабан туе бер генә, бер генә,
Күңел ачып йөр генә, йөр генә.
Җырла кияү, бие, килен,
Бии торган көнең бүген –
һоп!.. һоп-па!..
һоп!.. һоп-па!..

Туп-туп итеп атлар килә,
Тояклардан утлар сибә,
Чаткылар!
Чаткылар!
Батыр булсаң күтәреп ал,
Күтәреп ал, сыртына сал –
һоп!.. һоп-па!..
һоп!.. һоп-па!..
Сабан туе бер генә, бер генә,
Онтылмасын гомергә, гомергә.
Уйна, җырла көне буе,
Уртага ук төшеп бие –
һоп!.. һоп-па!..
һоп!.. һоп-па!..

Александр АЛЁШИН



